**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Сапеевского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Сэпэй авыл**
**җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Школьная, д.53В, село Сапеево,
Азнакаевского муниципального района, 423326
Тел. (факс) (8-85592) 44-2-40, факс 44-2-83
Sap.Azn@tatar.ru

Школьная урамы , 53В, Сэпэй авылы
Азнакай муниципаль районы, 423326
Тел. (факс) (8-85592) 44-2-40
Sap.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «07» ноября 2025г. №3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенең Мачаклыбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сәпәй авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итә:

1. 2025 елның 14 ноябрендә Мачаклы-Баш торак пунктында, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Мачаклы-Баш торак пункты, Урман буе урамы, 10 йорт каршында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенең Мачаклы-Баш торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 14 сәгать 00 минутка билгеләргә: Мачаклыбаш торак пунктында Урман буе урамы буенча 1нче йорттан 38а йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенең Мачаклыбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертүгә ризамы, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, бер тапкыр түләүне киметергә, аны 2 төркем инвалидлар

өчен 250 сум итеп билгеләп һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электр товарлары сатып алу, урам яктырткычларын һәм лампаларын алыштыру, урам яктырткычларын ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (сатып алу, төяү, ташу, вак таш салу, Урман буе урамындагы шартнамә буенча эшләр өчен түләү).

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чаптыру, куакларны кисү, чүп-чар җыю, Мачаклы - Баш авылы территориясен төзекләндерү өчен триммер сатып алу, запас частьләр ,триммер өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, трактор өчен чапкыч сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендына урнаштырып халыкка җиткерергә: Мачаклы-Баш авылы, Урман буе урамы, 15 йорт каршында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында бастырылган (http/ / aznakayevo.tatarstan. ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында () http://pravo.tatarstan.ru), кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге башлыгы — Ф.Г.Галиева